ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.06.2022 г.Лениногорск № 600

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 21 маендагы 494 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге өчен электрон формада үткәрелә торган конкурслар, аукционнар, котировкалар һәм тәкъдимнәр запрослары үткәргәндә товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 16 апрелендәге 104-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 21 маендагы 494 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге өчен электрон формада үткәрелә торган конкурслар, аукционнар, котировкалар һәм тәкъдимнәр запрослары үткәргәндә товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуны гамәлгә ашыру буенча бердәм комиссия турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.3 пунктының 3 абзацында «Салым кодексының 284 статьясының 3 пунктының 1 пунктчасы» сүзләрен «Бюджет кодексының 241 статьясының 15 пункты» сүзләре белән алмаштырырга, «салым салуның ташламалы салым

режимы һәм (яисә) юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналары) уздырганда мәгълүматны ачуны һәм тапшыруны күздә тотмаучылар» сүзләрен «Россия Федерациясе активларына арадаш (офшор) ия булу өчен кулланыла торган» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматынын рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Л.М.Галимова
5-44-72